РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2023г. г. Альметьевск № 214

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының XV бүлеге нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына 1 нче кушымта нигезендә тәкъдим ителгән үзгәрешләр проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр әзерләү буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен һәм катнашуларын исәпкә алу тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.

4. «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга:

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр әзерләү буенча комиссия составы;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм катнашу тәртибе;
- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты турында 4 нче кушымта нигезендә ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе.

5. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залында (Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт, 325 нче кабинет) 2023 елның 12 маенда 15.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

Комиссиягә Әлмәт муниципаль районында ачык тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә уставка үзгәрешләр кертү проектын тикшерүне һәм килгән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т. Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2023 елның
29 мартындагы 214 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында

1) 6 статьяның 1 өлешендәге 34 пунктны "федераль закон нигезендә" дип тулыландырырга;

2) 6.1 статьясының 1 өлешендәге 22 пунктны "федераль закон нигезендә" дип тулыландырырга;

3) 26 статьяда:

а) 2 өлешнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 өлештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

г) 9 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

д) 10 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

4) 28 статьяның 1 өлешендәге икенче җөмләсендә «алдагы» сүзеннән соң «чакырылыш» сүзен өстәргә, ә ул булмаганда, Район Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 29 статьяның 1 өлешендә:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) Районның Башкарма комитеты җитәкчесен, Районның Финанс-бюджет палатасы рәисен, районның Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты рәисен билгеләнү, аларның отставкасын кабул итү;

б) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) Районның Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәне, Районның Финанс-бюджет палатасы турындагы нигезләмәне һәм Районның Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты турындагы нигезләмәне раслау;

в) 15 пунктны төшереп калдырырга;

г) 38 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38) сайлау комиссиясе составына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү;»;

6) 35 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 1.1 өлеш өстәргә:

«1.1. Депутат җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән район Советының барлык утырышларына килмәгән очракта, Район Советы карары белән депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

7) 37 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга »;

8) 38 статьяда:

а) 2 өлешнең 2 пунктындагы «а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

9) 40 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

10) 44 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктындагы уникенче абзацында «федераль закон нигезендә» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешнең 3 пунктындагы сигезенче абзацында «федераль закон нигезендә» сүзләрен өстәргә;

11)45 статьяның 3.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Район Башкарма комитеты җитәкчесе:

1) Район Советына хисап бирә һәм контрольдә тота;

2) район советына үз эшчәнлеге һәм район Башкарма комитеты эшчәнлеге нәтиҗәләре, шул исәптән район Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында еллык хисаплар тапшыра;

3) район Башкарма комитеты тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә.»;

12) 49 статьяда:

а) 2 өлешнең 2 пунктында "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен»Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) " сүзләре белән алыштырырга;

б) 3 нче өлештә "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен» Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) " сүзләре белән алыштырырга;

13) 53 статьясының 2 өлеше түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Финанс-бюджет палатасы рәисе үз вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан билгеләнә.

Финанс-бюджет палатасы рәисе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән тикшерүне уздыруда Татарстан Республикасы финанс органының катнашу тәртибе «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта белән билгеләнә.»;

14) 55 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

15) 56 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә юридик зат хокукы Район Советы, Районның башкарма комитеты, Районның Контроль-хисап палатасы, Районның Финанс-бюджет палатасы, Районның Җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитетына бирелә.

2. Район Советы карары белән юридик зат хокуклары район башкарма комитеты структурасы нигезендә аның аерым органнарына бирелергә мөмкин..»;

16) 64.1 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

17) 65.1 статьяда:

а) 1 нче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен Татарстан Республикаасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 өлештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

е) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 11 өлешнең 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

з) 14 өлештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

18) 69 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хокукый актлар проектлары район башлыгы, район Советы депутатлары, Район Башкарма комитеты җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициативалы төркемнәре, Әлмәт шәһәр прокуроры, Районның Контроль-хисап палатасы, Районның Финанс-бюджет палатасы һәм Районның җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге комитеты тарафыннан аларны алып бару мәсьәләләре буенча кертелергә мөмкин.

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.»;

19) 92 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район уставы, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Советы карары дәүләт теркәве узганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм алар рәсми басылып чыкканнан соң әлеге Устав нигезендә, шулай ук «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм шулай ук Россия Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» порталында (http://pravo-minjust.ru, http://pravo-минюст.рф) урнаштырылырга тиеш. Район башлыгы теркәлгән Устав Район уставын, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карарын муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамә кергән көннән алып җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.».

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» • РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2023 елның
29 мартындагы 214 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр әзерләү буенча комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Зимин А.А. | Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе |
| 2. | Грушин А.И. | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Кичү авыл җирлеге вәкиле, бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссия рәисе |
| 3. | Парфилова Н.В. | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Әлмәт шәһәре вәкиле, законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе |
| 4. | Минһаҗев И.М. | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Борискино авыл җирлеге вәкиле, икътисади үсеш, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссия рәисе |
| 5. | Горбунова В.Н. | Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты, Аппак авыл җирлеге башлыгы |
| 6. | Әфләтунова Р.Е. | Әлмәт муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе |
| 7. | Ханнанова Ә.Б. | Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы |

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2023 елның
29 мартындагы 214 номерлы
карарына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен һәм катнашуларын исәпкә алу тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде, гражданнарның Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча аларның тәкъдимнәрен тикшерүдә катнашуын һәм исәпкә алуын билгели.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча тәкъдимнәр Әлмәт муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт:

| №№ п/п | Пункт, пунктча | Проект тексты | Төзәтмәнең тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып проект тексты | Нигез | Төзәтмә авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш урыны (уку), имза) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00-17.00 сәгатьләрдә (төшке аш тәнәфесе - 12.00-13.00 сәгатьләрдә) «Альметьевский вестник» газетасында ачык тыңлаулар уздырылган көнгә кадәр Әлмәт муниципаль районы Уставында үзгәрешләр проекты басылып чыккан көннән башлап кабул ителә.

3. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт яисә почта аша (“Устав турында” конвертта тамга белән), шулай ук 39-01-31 номерлы факс буенча, ачык тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча.

4. Гражданнарның тәкъдимнәре һәм ачык тыңлауларда катнашу өчен заявкалары Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының хатлар бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты буенча комиссиягә тапшырыла.

5. Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проектындагы үзгәрешләргә карата гына кертелә һәм федераль закон таләпләренә туры килергә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының башка нигезләмәләре белән каршылыкларга яки килешмәүчәнлеккә юл куймаска һәм район Уставының нигезләмәләрен берсүзсез аңлатуны тәэмин итәргә тиеш.

6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты, шулай ук ачык тыңлауларга чыгарылган гражданнар тәкъдимнәре яңа редакциядә Әлмәт муниципаль районында ачык тыңлауларны үткәрү турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә ачык тыңлауларда каралырга тиеш.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Советының 2023 елның
29 мартындагы 214 номерлы
карарына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр проекты турында ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе

1. Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Әлмәт муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында яңа редакциядә ачык тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә яраклы рәвештә үткәрелә.

2. Әлмәт муниципаль районы Уставы проекты һәм Әлмәт муниципаль районы советының Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары проекты Әлмәт муниципаль районы Советы аны кабул итү мәсьәләсен караган көнгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә бастырылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш. Бер үк вакытта әлеге проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, гражданнарның аны тикшерүдә катнашу тәртибе, шулай ук район Советының проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү турындагы карары басылып чыга.

Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Әлмәт муниципаль районы Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук район Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Әлмәт муниципаль районы Уставын әлеге норматив хокукый актлар нигезендә китерү максатларында Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелгәндә гражданнарның фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

3. Әлмәт муниципаль районы Уставы проекты яки Әлмәт муниципаль районы Советының район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары проекты буенча гавами тыңлаулар Әлмәт муниципаль районы Уставында билгеләнгән срокларда уздырыла, бу очракта Әлмәт муниципаль районы Уставында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында үзгәрешләр кертелә.

4. Ачык тыңлаулар уздыру турында карар басылып чыккан көннән алып аларны уздыру көненә кадәр район халкы ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр, кисәтүләр һәм төзәтмәләр җибәрергә хокуклы. Күрсәтелгән тәкъдимнәр, кисәтүләр һәм төзәтмәләр ачык тыңлауларда катнашучыларга җиткерелә.

5. Әлмәт муниципаль районы Уставы проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру буенча вәкаләтле орган яисә Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында акт карары проекты буенча комиссия була.

6. Халык алдында тыңлауларда район башлыгы, Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары, Әлмәт муниципаль районы Советының даими комиссияләре рәисләре рәислек итә ала. Утырыш ачык тыңлауларны ача, ачык тыңлауларның

сорауларын (сорауларын), тыңлауларны уздыру тәртибе буенча тәкъдимнәрне игълан итә, тыңлаулар үткәрү инициаторларын күрсәтә.

7. Вәкаләтле вәкил ачык тыңлаулар уздыру инициаторлары тарафыннан вәкаләт бирелгән затка, шулай ук чыгышларга хокукы булган ачык тыңлауларда катнашучыларга сүз бирә. Чыгышларның чираты комиссия тарафыннан теркәлгән гаризалар бирүнең чираты белән билгеләнә.

8. Тыңлауларда катнашучылар үз тәкъдимнәрен төшерергә һәм (яисә) ачык тыңлауларда башка катнашучылар күрсәткән тәкъдимнәргә кушылырга хокуклы.

9. Ачык тыңлаулар уздырган вакытта беркетмә алып барыла. Ачык тыңлаулар барышында керә торган барлык кисәтүләр һәм тәкъдимнәр ачык тыңлаулар секретарена җибәрелә.

10. Беркетмәгә ачык тыңлаулар рәислеге имза сала.

11. Ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә, ачык тыңлаулар уздырган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында йомгаклау төзелә.

12. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре комиссия рәисе тарафыннан имзалана һәм ачык тыңлаулар уздырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов